**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«_15_» 01 2019ел.** **№ __3___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 июлендәге 207 номерлы карары белән расланган «Мәгариф системасын мониторинглау кагыйдәләрен һәм күрсәткечләрен раслау турында» Азнакай муниципаль районы мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 23 июлендәге1124/18 номерлы «Татарстан Республикасында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы гомуми белем бирү муниципаль системалары мониторингын гамәлгә ашыру һәм аларны үткәрү тәртибе турында типлаштырылган нигезләмәне раслау хакында» боерыгын үтәү йөзеннән **карар бирәм:**

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф системасын мониторинглау кагыйдәләрен һәм күрсәткечләрен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 207 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.Мәгариф системасының торышы һәм үсеш перспективаларына үткәрелгән анализ нәтиҗәләре ел саен мәгариф Идарәсенең «Интернет» челтәрендә хисаптан соң килүче елның гыйнварында рәсми сайтында урнаштырыла.»

1.2. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Азнакай муниципаль районының гомуми белем бирү системасы мониторингы буенча тәкъдим ителгән нәтиҗәләр Азнакай муниципаль районының мәгариф системасы мониторингы күрсәткечләрен карау буенча муниципаль комиссия тарафыннан карала һәм раслана, аның составы әлеге карар белән раслана.

Мониторинг нәтиҗәләре агымдагы елның 10 августына Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенең хокукый акты белән раслана һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелә.».

1.3. Азнакай муниципаль районының мәгариф системасы мониторингы күрсәткечләрен карау буенча муниципаль комиссия составын, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати– телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб - адрес буенча: http/aznakayevo.tatar.ru һәм мәгариф Идарәсенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д. Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
«____» ________ 2019 № ______

**Азнакай муниципаль районы мәгариф системасы мониторингы күрсәткечләрен карау буенча муниципаль комиссия**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| *Комиссия рәисе:* | |
| Гилязов Дамир Рашат улы | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| *Комиссия рәисе урынбасарлары:* | |
| Рахманов Альберт Мөгаллим улы | МКУ " Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе" начальнигы |
| *Комиссиянең җаваплы секретаре:* | |
| Рәүпова Алия Ягъфәр кызы | "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" начальнигы урынбасары |
| *Комиссия секретаре:* | |
| Ганиуллина Әлфия Мирзаһит кызы | МКУ "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" өлкән методисты |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Әхмәдишина Лилия Мөгамбәр кызы | "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" начальнигы урынбасары |
| Мотыйгуллина Гөлназ Сабир кызы | МКУ «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе " методисты |
| Хәсәнова Рәмзия Миргасим кызы | Гомумроссия мәгариф профсоюзы Татарстан республика оешмасының Азнакай территориаль профсоюз оешмасы рәисе |